КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче Тимершык торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

26.08.2022 № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары , 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 29 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына таянып, 2022 елның 26 августында узган гражданнар җыенында «2023 нче елда Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенә керүче Тимершык торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Тимершык торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

-ТР Саба муниципаль районы Тимершык торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (Грунтны эшләү, ком нигезен урнаштыру, вак таштан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, суүткәргеч торбаларны җиһазлау, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 610 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 349 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 349 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче Тимершык торак пунктында халык җыенын үткән дип таныйрга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип таныйрга.
2. “2023 нче елда Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенә керүче Тимершык торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Тимершык торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) ТР Саба муниципаль районы Тимершык торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (Грунтны эшләү, ком нигезен урнаштыру, вак таштан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, суүткәргеч торбаларны җиһазлау, килешү буенча эшләр өчен түләү) карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/timershik адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Тимершык авыл
җирлеге башлыгы А.Х. Хаҗиев